**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 декабрендәге 5384 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 21 октябрендәге 4446 номерлы**
**«2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 16 статьясындагы 1 пунктның 13 пунктчасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 2025 елга башкарылган исәпләүләренә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 21 октябрендәге 4446 номерлы «2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-

икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 1.4 пунктча өстәргә:

«1.4. 2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләре милкен карап тоту нормативларын (элеге карарның 3 номерлы кушымтасы)»;

1.2. әлеге карарның кушымтасы нигезендә редакцияләнгән 3 номерлы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 декабрендәге
5384 номерлы карарына
кушымта

**2025 елга Казан шәһәренең**
**балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик,**
**хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни,**
**техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирә торган**
**мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирә торган**
**күппрофильле мәгариф учреждениеләре**
**милкен карап тоту нормативлары**

| **№ т/б** | **Балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениесе атамасы** | **Җылытыла торган мәйдан, кв.м** | **Милекне карап тоту нормативы, сум/кв.м елына** |
|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2628,6 | 1706,47 |
| 2 | Казан шәһәре Вахитов районының «Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3352,4 | 1130,26 |
| 3 | Казан шәһәре Вахитов районының «“Факел” балалар техник иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1782,2 | 222,76 |
| 4 | Казан шәһәренең «А.Алиш исемендәге шәһәр балалар иҗаты сарае» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 4566,24 | 1807,15 |
| 5 | Казан шәһәренең «Сәләтле балалар өчен иҗади үсеш һәм гуманитар белем | 0,0 | 0,0 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениесе атамасы | Җылытыла торган мәйдан, кв.м | Милекне карап тоту нормативы, сум/кв.м елына |
|---|---|---|---|
| | бирү шәһәр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | | |
| 6 | Казан шәһәренең «“Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе” мәгариф үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 120,5 | 3793,31 |
| 7 | Казан шәһәре Киров районының «“Заречье” балаларга өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3146,4 | 1671,21 |
| 8 | Казан шәһәре Киров районының «“Сәяхәт” балаларга өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1868,3 | 1490,66 |
| 9 | Казан шәһәре Мәскәү районының «Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1814,0 | 1407,95 |
| 10 | Казан шәһәренең «В.П.Чкалов исемендәге шәһәр балалар техник иҗат үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2122,8 | 1300,93 |
| 11 | Казан шәһәре Мәскәү районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2622,1 | 1365,07 |
| 12 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 626,8 | 4664,43 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениесе атамасы | Җылытыла торган мәйдан, кв.м | Милекне карап тоту нормативы, сум/кв.м елына |
|---|---|---|---|
| 13 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1120,5 | 2763,64 |
| 14 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «“Простор” балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 662,0 | 2282,17 |
| 15 | Казан шәһәре Идел буе районының «“Олимп” балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 838,3 | 3434,55 |
| 16 | Казан шәһәре Идел буе районының «“Молодость” балалар (яшүсмерләр) үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 511,2 | 1645,04 |
| 17 | Казан шәһәре Идел буе районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1737,5 | 2762,79 |
| 18 | Казан шәһәре Совет районының «Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 955,7 | 1313,05 |
| 19 | Казан шәһәре Совет районының «Азино» балалар иҗат үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 718,8 | 4755,53 |
| 20 | Казан шәһәре Совет районының «“Балалар академиясе” балалар иҗаты | 2666,1 | 1943,37 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениесе атамасы | Җылытыла торган мәйдан, кв.м | Милекне карап тоту нормативы, сум/кв.м елына |
|---|---|---|---|
| | үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | | |
| 21 | Казан шәһәре Совет районының «“Танкодром” балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 867,4 | 3646,55 |
| 22 | Казан шәһәренең «Балалар экология-биология шәһәр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1166,2 | 3602,79 |
| 23 | Казан шәһәре Совет районының «Дербышки поселогы балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2139,6 | 1768,14 |

___________________